РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ШЕМОРДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
422050, Республика Татарстан,
Сабинский район,
с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2
тел. (84362) 3-21-44

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШЭМЭРДЭН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
422050, Татарстан
Республикасы, Саба районы,
Шэмэрдэн авылы Лермонтов
урамы, 2 йорт
тел. (84362) 3-21-44

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
05.04.2021

КАРАР
№ 27 - п

Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл башкарма комитетының 2019 елның 23 апрелендә 81-п номерлы карары белән расланган агач һәм куаклар кисүгә, тепләүгә яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы финанс Министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте Идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык Идарәсенең 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча берләштерелгән коллегиясенең 2021 елның 04 гыйнварындагы ПР-3 номерлы беркетмәсен үтәү йөзеннән, Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 23 апрелендә 81-п номерлы карары белән расланган агач һәм куак кисүгә, тепләүгә яисә утыртуга рехсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Башкарма комитет сәркатибе электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша җавап бирү турында сорау җибәрә:

1) Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан еземтә (күчемсез милек объектына төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматлар).

2) Законнарны бозган өчен штрафлар, салымнар, җыемнар, пенялар һәм түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында белешмәләр.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән сорау.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә

http://pravo.tatarstan.ru адресы һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/shemordan адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы А.Н.Гәрәев